**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Карамалы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Карамалы авылы №107 21 сентябрь 2018 ел

Карамалы авылы җирлеге биләмәсендә
үзарасалым җыю һәм куллану
буенча, җирле референдум үткәрү
көнен билгеләү турында.

2002 елның 12 июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре” турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның уртак принциплары” турындагы 113 номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән “Җирле референдум” турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Карамалы авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Карамалы авыл җирлеге башлыгының 2018 елның 07 сентябрендә чыккан 15нче номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары, Карамалы авыл җирлеге Советының 2018 елның 07 сентябрендә чыккан 106нчы номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары нигезләрендә,

Карамалы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Карамалы авыл җирлеге биләмәсендә узара салым җыю һәм куллану буенча 2018нче елның 18нче ноябрендә референдум үткәрергә.
2. Референдумда караласы мәсьәлә:
“Сез, Карамалы авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2019 елда 250 сум күләмендә узарасалым җыю белән килешәсезме. Узарасалым түләүдән көндезге бүлекләрдә укучы студентлар, 1 группа инвалидлар азат ителә. Узарасалымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:

1) Җирле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге җирлек торак пунктлары чикләрендә әһәмияттәге мәсьәләләр:

-Карамалы авылында Совет урамы, Профсоюз урамы, Таллы Бүләк авылы, Лесная урамы буенча юлларга таш җәю;

2) Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Карамалы, Таллы Бүләк, Октябрь Бүләк авылларында урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, электр товарлар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм

аларга хезмәт күрсәтү);
- авыл җирлеге территориясендә чүп үләнен чабу;
- авыл җирлеге территориясендә юлларны кардан чистарту;
-Таллы Бүләк, Октябрь Бүләк авылларына балалар мәйданчыклары элементларын сатып алу һәм урнаштыру;

3) Җирлек халкының ял итүен оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәте белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру:
- Карамалы авылы мәдәният йорты тамбурын ремонтлау;

4) Ритуаль хезмәтләрне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:
- Карамалы авылы зират коймаларын төзәтү;

5) Җирлек халкы күпләп ял итә алсын өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына ирекле үтеп керүен тәэмин итү:
- Октябрь-Бүләк авылында парк оештыру өчен урман посадкасы территориясен койма белән әйләндереп алу;

6) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, су бүлү, халыкны ягулык белән тәэмин итүне җирлек чикләрендә оештыру:
- су насосы сатып алу.

ӘЙЕ ЮК

3. Карар районның “Маяк” газетасында бастырыла һәм Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә http://aznakyevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча урнаштырыла.
4. Карар газетада бастырылып чыккан көненнән көченә керә.

Председатель Ногманов А.Р.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАРАМАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
КАРАМАЛИНСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЗНАКАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН